# И БӘРӘҢГЕ!

Авылда син еллар буе
Кулдан төшмисең.
Эре булсын уңышлы, дип,
Көн-төн эшлисе.

Тир түгәбез, көч салабыз
Сиңа күпме без.
Ә аннан соң сабагыңнан
Коңгыз чүплибез.

Табында син аш булганчы,
Бәрәңге, җаным,
Суырасың күпме көчне,
Йөрәкнең канын.

Өчпочмак, шәңгә, тәкәсе,
Майлы күзикмәк...
Һәйкәл кирәк бәрәңгегә –
Ул бит төп икмәк!